ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 118-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Н.Н. Хаҗипов, Р.Ф. Комаров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 118-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 29 октябре
№ 437-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.К. Хамаев, Н.Н. Хаҗипов,
Р.Ф. Комаров тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 9 статьясындагы 3 пунктына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 18 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 75 (I өлеш), «аквакультура (балыкчылык)» сүзләреннән соң «, гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясындагы 1 өлешенең алтынчы абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш), № 12 (X өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2012, № 1, № 9; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш); 2024, № 47 (I өлеш), «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органыннан яисә Татарстан Республикасы җирле үзидарә органыннан торак йорт төзү өчен билгеләнгән тәртиптә җир кишәрлеге (бакча өчен җир

кишәрлегеннән тыш)» сүзләрен «торак йорт төзү өчен билгеләнгән тәртиптә дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеге» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының 98 статьясындагы 14[1] өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 86 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш), № 47 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), № 75 (I өлеш), «Су саклау зоналары чикләрендә урнашкан һәм агып төшүче суларны чистарту корылмалары белән җиһазландырылмаган, гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территорияләренә карата» сүзләрен «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өчен су саклау зоналары чикләрендә урнашкан территориядә агып төшүче суларны чистарту корылмалары булмаса,» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**4 статья**

«Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 73 (I өлеш); 2024, № 76 (I өлеш); 2025, № 75 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 10 пунктында «коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яисә) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен» сүзләреннән соң «һәм гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе чикләрендә урнашкан бакча җир кишәрлекләре һәм яшелчә җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларны» сүзләрен өстәргә;

2) 6 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында «шулай ук» сүзләреннән соң «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе чикләрендәге» сүзләрен өстәргә;

3) 7 статьяның 1 пунктындагы «ж» пунктчасында «коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яисә) коммерциягә карамаган яшелчәчелек

ширкәтләрен» сүзләрен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе чикләрендәге коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яисә) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен» сүзләренә алмаштырырга.

**5 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 21 июнендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2022, № 49 (I өлеш), № 90 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 3 пунктында «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

2) 6 статьяның 1 өлешендә:

а) 4 пунктта «җылылык һәм электр энергиясе, су, газ белән тәэмин итүне, су җибәрүне, ягулык белән тәэмин итүне» сүзләрен «җылылык, электр, газ, су белән тәэмин итүне, су җибәрүне тәэмин итүне, каты коммуналь калдыклар белән эш итүне» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 пунктта «дәүләт милкенә» сүзләрен «милкенә» сүзенә алмаштырырга.

**6 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законы проекты 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә кергән «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 353-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Әлеге Федераль закон белән гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендәге хокук мөнәсәбәтләрен камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең берничә закон актына законнардагы терминологик туры килмәүләрне һәм билгесезлекләрне, шулай ук редакцион төгәлсезлекләрне бетерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелде. Аерым алганда, үзгәрешләр «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законга, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-I номерлы Россия Федерациясе законына, Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясе Су кодексына кертелде.

Федераль законнардагы бу үзгәрешләр Татарстан Республикасы Җир кодексына, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Экология кодексына, «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 21 июнендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү зарурлыгына китерде.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә түбәндәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына үзгәрешләр кертү таләп ителәчәк:

«Җир өчен аренда түләве турында» 1995 елның 9 февралендәге 74 номерлы;

«Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгының саклау зонасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2002 елның 19 апрелендәге 217 номерлы;

«Зәңгәр күлләр» региональ әһәмияттәге комплекслы профильле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 елның 16 мартындагы 324 номерлы;

«Мишә» региональ әһәмияттәге дәүләт табигать зоологик (аучылык) заказнигы турында» 2004 елның 29 гыйнварындагы 41 номерлы;

«А.П. Пухачев исемендәге «Чулпан» региональ әһәмияттәге ландшафт профильле дәүләт табигать заказнигы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 19 августындагы 379 номерлы;

«Әгерҗе», «Биләр», «Сурнар» региональ әһәмияттәге дәүләт табигать зоологик (аучылык) заказниклары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2004 елның 17 ноябрендәге 494 номерлы;

«Свияжск» региональ әһәмияттәге комплекслы профильле дәүләт табигать заказнигы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 14 гыйнварындагы 1 номерлы;

«Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 316 номерлы;

«Чатыр-Тау» региональ әһәмияттәге комплекслы профильле дәүләт табигать заказнигы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 18 июлендәге 353 номерлы;

«Чиста болыннар» региональ әһәмияттәге комплекслы профильле дәүләт табигать заказнигы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 31 октябрендәге 513 номерлы;

«Спас» региональ әһәмияттәге комплекслы профильле дәүләт табигать заказнигы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 23 ноябрендәге 549 номерлы;

«Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм аларда товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) тәртибен раслау турында» 2011 елның 4 мартындагы 171 номерлы;

«Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше проектлавының республика нормативларын раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1071 номерлы;

«Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге табигать һәйкәлләре турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2019 елның 29 мартындагы 237 номерлы;

«Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе чикләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы мөлкәтне Татарстан Республикасы дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә түләүсез алу тәртибен раслау турында» 2019 елның 30 мартындагы 243 номерлы;

«Югары Ослан, Зеленодольск, Кама Тамагы, Лаеш муниципаль районнары, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә «Идел киңлекләре» региональ әһәмияттәге ландшафт профильле дәүләт табигать заказнигын төзү турында» 2019 елның 30 декабрендәге 1260 номерлы;

«Татарстан Республикасы Әгерҗе, Актаныш, Минзәлә һәм Тукай муниципаль районнары территориясендә «Кама-Ык» региональ әһәмияттәге комплекслы профильле дәүләт табигать заказнигын төзү турында» 2020 елның 28 августындагы 751 номерлы;

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә «Агыйдел елгасы дельтасы» региональ әһәмияттәге комплекслы профильле дәүләт табигать заказнигын төзү турында» 2020 елның 31 августындагы 761 номерлы;

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендәге «Маняуз үзәне», Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы территориясендәге «Покш Пандо» табигать объектларын региональ әһәмияттәге табигать һәйкәлләре итеп игълан итү турында» 2020 елның 29 сентябрендәге 881 номерлы;

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендәге «Соколка утравы» табигать объектын региональ әһәмияттәге табигать һәйкәле итеп игълан итү турында» 2021 елның 27 маендагы 381 номерлы;

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендәге «Чепья урманы» табигать объектын региональ әһәмияттәге табигать һәйкәле итеп игълан итү турында» 2022 елның 4 июлендәге 622 номерлы;

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендәге «Екатериновка авылы янындагы урман массивы» табигать объектын региональ әһәмияттәге табигать һәйкәле итеп игълан итү турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1113 номерлы;

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә «Байбаклар колониясе» региональ әһәмияттәге биологик (зоологик) профильле дәүләт табигать заказнигын төзү турында» 2025 елның 29 сентябрендәге 780 номерлы;

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә «Зур ак челәннең оялау урыннары» региональ әһәмияттәге биологик (зоологик) профильле дәүләт табигать заказнигын төзү турында» 2025 елның 30 сентябрендәге 782 номерлы.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итмәячәк.